**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан**

В связи с изменениями в федеральном законодательстве в области гражданской обороны **постановляю**:

1. Внести в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-598 «Об утверждении Положения об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 17 октября 2014 года № УП-995, от 19 января 2016 года № УП-18, от 4 июня 2016 года № УП-502 и от 27 января 2020 года № УП-27), следующие изменения:

а) в пункте 2.4:

в абзаце пятом слова «об угрозе возникновения или о возникновении чрезвычайных ситуаций» заменить словами «при чрезвычайных ситуациях»;

в абзаце девятом слова «об угрозе возникновения или о возникновении чрезвычайных ситуаций» заменить словами «при чрезвычайных ситуациях»;

б) раздел 3 изложить в следующей редакции:

«3. Мероприятия по гражданской обороне

Органы исполнительной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления и организации в целях решения задач в области гражданской обороны в соответствии с установленными федеральным законодательством полномочиями планируют и осуществляют следующие мероприятия:

3.1. по подготовке населения в области гражданской обороны:

развитие нормативно-методического обеспечения функционирования единой системы подготовки населения в области гражданской обороны и защиты от чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера;

планирование и осуществление обучения населения в области гражданской обороны;

создание, оснащение и всестороннее обеспечение деятельности Учебно-методического центра по гражданской обороне и чрезвычайным ситуациям Республики Татарстан, других организаций дополнительного профессионального образования должностных лиц и работников гражданской

обороны, учебно-консультационных пунктов по гражданской обороне, а также обеспечение функционирования курсов гражданской обороны муниципальных образований;

создание и поддержание в рабочем состоянии учебной материально-технической базы для подготовки работников организаций в области гражданской обороны;

пропаганда знаний в области гражданской обороны;

3.2. по оповещению населения об опасностях, возникающих при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:

создание и поддержание в состоянии постоянной готовности системы централизованного оповещения населения, осуществление ее модернизации на базе технических средств нового поколения;

создание и поддержание в состоянии готовности локальных систем оповещения организациями, эксплуатирующими опасные производственные объекты I и II классов опасности, особо радиационно опасные и ядерно опасные производства и объекты, последствия аварий на которых могут причинять вред жизни и здоровью населения, проживающего или осуществляющего хозяйственную деятельность в зонах воздействия поражающих факторов за пределами их территорий, гидротехнические сооружения чрезвычайно высокой опасности и гидротехнические сооружения высокой опасности;

установка специализированных технических средств оповещения и информирования населения в местах массового пребывания людей;

комплексное использование средств единой сети электросвязи Российской Федерации, сетей и средств радио-, проводного и телевизионного вещания, а также других технических средств передачи информации;

сбор информации в области гражданской обороны и обмен ею;

3.3. по эвакуации населения, материальных и культурных ценностей в безопасные районы:

организация планирования, подготовки и проведения эвакуации;

подготовка безопасных районов для размещения населения, материальных и культурных ценностей, подлежащих эвакуации;

создание и организация деятельности эвакуационных органов, а также подготовка их личного состава;

3.4. по предоставлению населению средств индивидуальной и коллективной защиты:

строительство, сохранение, поддержание в состоянии постоянной готовности к использованию по предназначению и техническое обслуживание защитных сооружений гражданской обороны и их технических систем;

приспособление в мирное время, при приведении гражданской обороны в готовность к ее ведению и в ходе ее ведения в военное время заглубленных помещений и других сооружений подземного пространства для укрытия населения;

подготовка в мирное время и строительство при приведении гражданской обороны в готовность к ее ведению и в ходе ее ведения в военное время быстровозводимых защитных сооружений гражданской обороны с упрощенным внутренним оборудованием и укрытий простейшего типа;

обеспечение укрытия населения в защитных сооружениях гражданской обороны, в заглубленных помещениях и других сооружениях подземного пространства;

накопление, хранение, освежение и использование по предназначению средств индивидуальной защиты;

обеспечение выдачи населению средств индивидуальной защиты и предоставления средств коллективной защиты в установленные сроки;

приспособление в мирное время метрополитена для укрытия населения с учетом опасностей мирного и военного времени, наличия защитных сооружений гражданской обороны и планируемых мероприятий по гражданской обороне и защите населения;

3.5. по световой маскировке и другим видам маскировки:

определение перечня объектов, подлежащих маскировке;

разработка планов осуществления комплексной маскировки территорий, отнесенных в установленном порядке к группам по гражданской обороне, а также организаций, являющихся вероятными целями при использовании современных средств поражения;

создание и поддержание организациями, отнесенными в установленном порядке к категориям по гражданской обороне, в состоянии постоянной готовности к использованию по предназначению запасов материально-технических средств, необходимых для проведения мероприятий по световой маскировке и другим видам маскировки;

проведение инженерно-технических мероприятий по уменьшению демаскирующих признаков организаций, отнесенных в установленном порядке к категориям по гражданской обороне;

3.6. по проведению аварийно-спасательных и других неотложных работ в случае возникновения опасности для населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:

создание, оснащение и подготовка необходимых сил и средств гражданской обороны и единой государственной системы предупреждения и ликвидации чрезвычайных ситуаций, а также планирование их действий;

создание и поддержание в состоянии постоянной готовности к использованию по предназначению запасов материально-технических, продовольственных, медицинских и иных средств для всестороннего обеспечения аварийно-спасательных работ;

разработка современных технологий и технических средств для проведения аварийно-спасательных работ;

организация взаимодействия сил гражданской обороны с Вооруженными Силами Российской Федерации, другими войсками,

воинскими формированиями и органами, а также со специальными формированиями, создаваемыми в военное время;

учет и ведение реестров нештатных аварийно-спасательных формирований, привлекаемых для решения задач в области гражданской обороны, и нештатных формирований по обеспечению выполнения мероприятий по гражданской обороне;

3.7. по первоочередному жизнеобеспечению населения, пострадавшего при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:

планирование и организация основных видов жизнеобеспечения населения;

создание и поддержание в постоянной готовности к использованию по предназначению запасов материально-технических, продовольственных, медицинских и иных средств;

нормированное снабжение населения продовольственными и непродовольственными товарами;

предоставление населению коммунально-бытовых услуг;

проведение санитарно-гигиенических и противоэпидемических мероприятий среди населения, пострадавшего при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов;

осуществление эвакуации пострадавших в лечебные учреждения;

определение численности населения, оставшегося без жилья;

инвентаризация сохранившегося и оценка состояния поврежденного жилого фонда, определение возможности его использования для размещения пострадавшего населения, размещение людей, оставшихся без жилья, в домах отдыха, пансионатах и других оздоровительных учреждениях, временных жилищах (сборных домах, палатках, землянках и т.п.), а также осуществление подселения населения на площадь сохранившегося жилого фонда;

предоставление населению информационно-психологической поддержки;

3.8. по борьбе с пожарами, возникшими при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов:

создание необходимых противопожарных сил, их оснащение материально-техническими средствами и подготовка в области гражданской обороны;

тушение пожаров в районах проведения аварийно-спасательных и других неотложных работ в военное время;

тушение пожаров на объектах, отнесенных в установленном порядке к категориям по гражданской обороне, в военное время;

3.9. по обнаружению и обозначению районов, подвергшихся радиоактивному, химическому, биологическому или иному заражению:

создание и обеспечение готовности сети наблюдения и лабораторного контроля гражданской обороны и защиты населения – действующих специализированных учреждений, подразделений и служб органов государственной власти Республики Татарстан и организаций,

осуществляющих функции наблюдения и контроля за радиационной, химической, биологической обстановкой на территории Республики Татарстан;

введение режимов радиационной защиты на территориях, подвергшихся радиоактивному заражению (загрязнению);

совершенствование методов и технических средств мониторинга за радиационной, химической, биологической обстановкой, в том числе за степенью зараженности (загрязнения) продовольствия и объектов окружающей среды радиоактивными, химическими и биологическими веществами;

3.10. по санитарной обработке населения, обеззараживанию зданий и сооружений, специальной обработке техники и территорий:

заблаговременное создание запасов дезактивирующих, дегазирующих и дезинфицирующих веществ и растворов;

создание сил гражданской обороны для проведения санитарной обработки населения и обеззараживания техники, зданий и территорий, а также их оснащение и подготовка в области гражданской обороны;

организация проведения мероприятий по обеззараживанию техники, зданий и территорий, санитарной обработке населения;

3.11. по восстановлению и поддержанию порядка в районах, пострадавших при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:

создание сил охраны общественного порядка, их оснащение материально-техническими средствами и подготовка в области гражданской обороны;

восстановление и охрана общественного порядка, обеспечение безопасности дорожного движения в городах и других населенных пунктах, на маршрутах эвакуации населения и выдвижения сил гражданской обороны;

усиление охраны объектов, подлежащих обязательной охране войсками национальной гвардии Российской Федерации, и имущества юридических и физических лиц (на основании соответствующих договоров), принятие мер по охране имущества, оставшегося без присмотра;

3.12. по вопросам срочного восстановления функционирования необходимых коммунальных служб в военное время:

обеспечение готовности коммунальных служб к работе в условиях военного времени и планирование их действий;

создание запасов оборудования и запасных частей для ремонта поврежденных систем газо-, энерго- и водоснабжения;

создание и подготовка резерва мобильных средств для очистки, опреснения и транспортировки воды;

создание на водопроводных станциях необходимых запасов реагентов, реактивов, консервантов и дезинфицирующих средств;

создание запасов резервуаров и емкостей, сборно-разборных трубопроводов, мобильных резервных и автономных источников энергии, другого необходимого оборудования и технических средств;

3.13. по срочному захоронению трупов в военное время:

заблаговременное определение мест возможных захоронений;

создание, подготовка и поддержание в готовности сил и средств гражданской обороны для обеспечения мероприятий по срочному захоронению трупов, в том числе на базе специализированных ритуальных организаций;

организация и проведение мероприятий по опознанию, учету и захоронению трупов с соблюдением установленных законодательством правил;

организация санитарно-эпидемиологического надзора;

3.14. по обеспечению устойчивости функционирования организаций, необходимых для выживания населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:

создание и организация работы в мирное и военное время комиссий по вопросам повышения устойчивости функционирования объектов экономики;

рациональное размещение населенных пунктов, объектов экономики и инфраструктуры, а также средств производства в соответствии с требованиями строительных норм и правил осуществления инженерно-технических мероприятий гражданской обороны;

разработка и проведение мероприятий, направленных на повышение надежности функционирования систем и источников газо-, энерго- и водоснабжения;

разработка и реализация в мирное и военное время инженерно-технических мероприятий гражданской обороны;

планирование, подготовка и проведение аварийно-спасательных и других неотложных работ на объектах экономики, продолжающих работу в военное время;

заблаговременное создание запасов материально-технических, продовольственных, медицинских и иных средств, необходимых для сохранения и (или) восстановления производственного процесса;

создание страхового фонда документации;

повышение эффективности защиты производственных фондов при воздействии на них современных средств поражения;

3.15. по вопросам обеспечения постоянной готовности сил и средств гражданской обороны:

создание и оснащение современными техническими средствами сил гражданской обороны;

подготовка сил гражданской обороны, проведение учений и тренировок по гражданской обороне;

планирование действий сил гражданской обороны;

разработка высокоэффективных технологий для проведения аварийно-спасательных и других неотложных работ;

определение порядка взаимодействия и привлечения сил и средств гражданской обороны, а также всестороннее обеспечение их действий.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
23 апреля 2022 года
№ УП-297

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Граждан оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы, 2016 елның 4 июнендәге ПУ-502 номерлы һәм 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.4 пунктта:

бишенче абзацта «гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы яисә килеп чыгуы турында» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы яисә килеп чыгуы турында» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Граждан оборонасы буенча чаралар

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар федераль законнар белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә граждан оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында түбәндәге чараларны планлаштыра һәм тормышка ашыра:

3.1. граждан оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча:

граждан оборонасы һәм табигый, техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклану өлкәсендә халыкны әзерләү буенча бердәм системаның эшләвен норматив-методик тәэмин итүне үстерү;

халыкны граждан оборонасы өлкәсендә өйрәтүне планлаштыру һәм тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы граждан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр укыту-методика үзәген, вазыйфаи затларга һәм граждан оборонасы хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүнең башка оешмаларын, граждан оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазлау, аларның эшчәнлеген һәрьяклап тәэмин итү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең граждан оборонасы курслары эшчәнлеген тәэмин итү;

граждан оборонасы өлкәсендә оешмалар хезмәткәрләрен әзерләү өчен укыту матди-техник база булдыру, аны төзек хәлдә тоту;

граждан оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау.

3.2. хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләрнең нәтиҗәсе буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр туу куркынычы турында халыкка хәбәр итү буенча:

халыкка хәбәр бирүнең үзәкләштерелгән системасын булдыру һәм аны даими рәвештә әзерлек хәлендә тоту, яңа буын техник чаралар базасында аны яңартып коруны тормышка ашыру;

I һәм II куркынычлылык классындагы җитештерү объектларын, аларда булган һәлакәтләр нәтиҗәләре әлеге объектлар урнашкан территорияләр чигеннән тыштa зыян китерү факторы йогынты ясый ала торган зоналарда яшәүче һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баручы кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерергә мөмкин аеруча көчле радиация куркынычы һәм атом-төш куркынычы булган җитештерүләрне һәм объектларны, гадәттән тыш югары дәрәҗәдә куркынычлы гидротехник корылмаларны һәм югары дәрәҗәдә куркынычлы гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмаларда хәбәр итүнең локаль системаларын булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту;

кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат тапшыруның махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясе бердәм электр элемтәсе челтәреннән, радиочелтәрләреннән һәм чараларыннан, чыбыклы элемтә һәм телевидение аша, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

граждан оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу.

3.3. халыкны, матди һәм мәдәни хәзинәләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләү буенча:

эвакуацияне планлаштыру, әзерләү һәм уздыруны оештыру;

куркыныч янамый торган районнарны эвакуацияләнергә тиешле кешеләрне, матди һәм мәдәни хәзинәләрне урнаштыру өчен әзерләү;

эвакуация уздыра торган органнар булдыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү.

3.4. халыкны шәхси һәм күмәк саклану чаралары белән тәэмин итү буенча:

граждан оборонасы саклану корылмаларын һәм аларның техник системаларын төзү, саклау, аларны билгеләнеше буенча даими файдалануга әзерлек хәлендә тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү;

тыныч вакытта һәм граждан оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчерүгә әзерлек вакытында һәм күчерү барышында казып эшләнгән биналарны һәм җир асты киңлекләренең башка корылмаларын халыкка яшеренү өчен яраклаштыру;

граждан оборонасының тиз арада төзелә торган, эчке җиһазлары гади саклану корылмаларын һәм гади типтагы яшеренү урыннарын тыныч вакытта әзерләү һәм граждан оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә төзү;

халыкның граждан оборонасы саклану корылмаларында, казып эшләнгән биналарда һәм җир асты киңлекләренең башка корылмаларында яшеренүен тәэмин итү;

шәхси саклану чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча файдалану;

билгеләнгән вакытларда халыкка шәхси саклану чаралары бирүне һәм күмәк саклану чараларын тапшыруны тәэмин итү;

тыныч вакытта һәм сугыш вакытында куркыныч килеп туганда, граждан оборонасы саклану корылмаларын һәм граждан оборонасы һәм халыкны саклау буенча планлаштырыла торган чараларны да кертеп, тыныч вакытта метрополитенны халыкка яшеренү өчен җайлаштыру.

3.5. яктылыкны маскировкалау һәм маскировкалауның башка төрләре буенча:

маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

граждан оборонасы буенча категорияләргә кертелгән оешмаларны комплекслы маскировкалау планнарын эшләү;

яктылыкны маскировкалау һәм маскировкалауның башка төрләре буенча чаралар уздыруны кирәк булган матди-техник чаралар запасларын билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту һәм булдыру;

граждан оборонасы буенча билгеләнгән тәртиптә тиешле категорияләргә кертелгән оешмаларның җитәрлек дәрәҗәдә маскировкаланмаган булуын бетерү буенча инженер-техник чараларны уздыру.

3.6. хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак, шулай ук табигый һәм техноген характердагы һәм террорлык актлары нәтиҗәсендә килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкка куркыныч янаган очракта һәлакәттән коткару эшләре уздыру буенча:

граждан оборонасының тиешле көчләрен һәм чараларын, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүнең бердәм дәүләт системасын булдыру, аларны коралландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар булдыру һәм аларны билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләр уздыруның заманча технологияләрен һәм техник чараларын эшләү;

гражданн оборонасы көчләренең Россия Федерациясе Кораллы Көчләре, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнар, шулай ук сугыш чорында төзелә торган махсус формированиеләр белән хезмәттәшлеген оештыру;

граждан оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итүгә җәлеп ителә торган штаттан тыш һәлакәт-коткару формированиеләре, граждан оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче штаттан тыш формированиеләр реестрын исәпкә алу һәм реестрларны алып бару.

3.7. хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләргә беренче чиратта, шул исәптән, башлангыч медицина ярдәме күрсәтүне, аларны ашыгыч рәвештә торак белән һәм башка кирәкле чаралар күрүне дә кертеп, тәэмин итү буенча:

халыкның тормышын тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын билгеләнеше буенча тәэмин итүне булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту;

халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалар буенча тәэмин итү;

халыкка коммуналь-көнкүреш һәм башка хезмәтләр күрсәтү;

хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләр арасында санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар уздыру;

зыян күргән кешеләрне дәвалау учреждениеләренә эвакуацияләү;

тораксыз калган кешеләрнең санын билгеләү;

торак фондының сакланып калган өлешен инвентарьлаштыру һәм зарарланган өлешенең торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен алардан файдалану мөмкинлекләрен билгеләү, зыян күргән кешеләрне ял йортларында, пансионатларда һәм башка савыктыру учреждениеләрендә, вакытлы торакларда (җыелмалы йортларда, палаткаларда, землянкаларда һ.б.ш.) урнаштыру, шулай ук аларны сакланып калган торак фонды биналарына урнаштыру;

халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү.

3.8. хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә килеп чыккан янгыннарга каршы көрәш буенча:

граждан оборонасы өлкәсендә янгыннарга каршы көрәшү өчен кирәкле көчләрне туплау, аларны коралландыру һәм әзерләү;

сугыш вакытында һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләр уздыру районнарында янгыннарны сүндерүне оештыру;

сугыш вакытында билгеләнгән тәртиптә граждан оборонасы буенча төрле категорияләргә кертелгән объектларда янгыннарны сүндерүне оештыру.

3.9. Радиактив, химик, биологик һәм башка төрле зарарлануга дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча:

Татарстан Республикасы территориясендә радиацион, химик, биологик хәлне күзәтү һәм контрольдә тоту функциясен башкаручы гамәлдә булган махсус учреждениеләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалар бүлекчәләре һәм хезмәтләре – граждан оборонасы һәм халыкны саклауның күзәтү һәм лаборатор контроль челтәрен булдыру һәм аның әзерлеген тәэмин итү;

радиоактив матдәләр белән зарарланган (пычранган) территорияләрдә радиациядән саклану режимнарын кертү;

радиацион, химик, биологик хәлне, шул исәптән азык-төлекнең һәм әйләнә-тирә мохит объектларының радиоактив, химик һәм биологик матдәләр белән зарарлану (пычрану) дәрәҗәсен мониторинглау ысулларын һәм техник чараларын камилләштерү;

3.10. халыкны санитар эшкәртү, биналарга һәм корылмаларга дезинфекция ясау, техникага һәм территорияләргә махсус эшкәртү уздыру:

дезактивацияләү, газсызландыру матдәләре һәм эремәләре запасларын алдан ук хәстәрләү;

халыкны санитар эшкәртүне, биналарга һәм корылмаларга дезинфекция ясауны, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртүне уздыру өчен көчләр булдыру һәм аларны коралландыру, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерлекле итү;

халыкны санитар эшкәртү, биналар һәм корылмаларны дезинфекцияләү, техника һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча чаралар уздыруны планлаштыру һәм оештыру.

3.11. хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау:

иҗтимагый тәртипне саклау көчләрен булдыру һәм коралландыру, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерлекле итү;

иҗтимагый тәртипне торгызу һәм саклау, гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт итүе һәм халыкны эвакуацияләү маршрутларында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү;

Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны, юридик һәм физик затларның (тиешле шартнамәләр нигезендә) мөлкәтен саклауны көчәйтү, иясез калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү.

3.12. сугыш чорында иң кирәкле коммуналь хезмәтләрнең эшчәнлеген ашыгыч рәвештә торгызу мәсьәләләре буенча:

сугыш чоры шартларында коммуналь хезмәтләрнең эшкә әзерлеген тәэмин итү, аларның эшчәнлек планнарын эшләү;

газ, электр энергиясе һәм су белән тәэмин итүнең зыян күргән системаларын төзекләндерү өчен җайланмалар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

суны чистарту, тозсызландыру һәм аны ташу өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

суүткәргеч станцияләрдә реагентларның, реактивларның, консервантларның һәм дезинфекция ясау чараларының кирәк кадәр запасларын булдыру;

халыкны коммуналь тәэмин итүне оештыру өчен резервуарлар һәм савытлар, җыела-сүтелә торган торбаүткәргечләр, күчмә резерв һәм автоном электр энергиясе чыганаклары, җайланмалар һәм техник чаралар запасларын булдыру.

3.13. сугыш вакытында мәетләрне ашыгыч җирләү буенча:

киләчәктә җирләү өчен кулланылу ихтималы булган урыннарны тыныч вакытта алдан ук билгеләп кую;

мәетләрне җирләү буенча, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында җирләү буенча да, гамәлләр кылуны тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм тәэмин итү;

законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, мәетләрне тану, исәпкә алу һәм җирләү эшләрен оештыру;

санитария-эпидемиология күзәтчелеген оештыру.

3.14. хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:

икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссияләр төзү һәм тыныч чорда һәм сугыш чорында аларның эшен оештыру;

торак пунктларны, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү җиһазларын төзелеш нормалары таләпләренә һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләренә туры китереп рациональ урнаштыру;

газ, электр энергиясе һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганаклары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттыруга юнәлтелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

тыныч чорда һәм сугыш чорында граждан оборонасының инженер-техник чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сугыш вакытында эшен дәвам иткән икътисад объектларында һәлакәт-коткару эшләрен һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

җитештерү процессын саклау һәм (яисә) торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка шундый чаралар запасын алдан ук булдыру;

иминиятләштерү документлары фондын булдыру;

аларга хәзерге заман зарарлы матдәләре йогынты ясаган очракта җитештерү фондларын саклауның нәтиҗәлелеген арттыру.

3.15. граждан оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча:

граждан оборонасы көчләрен булдыру һәм заманча техника һәм җайланмалар белән тәэмин итү;

граждан оборонасы көчләрен әзерләү, граждан оборонасы буенча күнегүләр һәм өйрәнүләр уздыру;

граждан оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

һәлакәт-коткару эшләрен һәм башка кичектергесез эшләрне башкару өчен югары нәтиҗәле технологияләрне эшләү;

граждан оборонасы көчләренең һәм чараларының үзара хезмәттәшлеге һәм аларны җәлеп итү тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 23 апрель
№ ПУ-297